# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Сәрдек торак пункты

22 сентябрь 2023 ел № 14

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сәрдек торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «Үзара салым акчаларының су скважинасы өчен бер су кудыру насосы алудан экономияләнгән өлешен су башнясының урынын алмаштырып ремонтлауга тотарга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында http://baltasi.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Заляев